*Сафа Мөхәммәтшан*

## ХӘТЕРДӘ САКЛАНГАННАРДАН

«Сәгъди абзый тәрбиягә[1] чит авылдан бала алып кайткан» дигәч, авыл балалары белән җыйнаулашып аны карарга бардык. Ул — шәһәрчәрәк киенгән, ак чырайлы, кечкенә гәүдәле, бик ябык, чандыр малай иде. Беренче күрүдә үк ул малай миңа ошады. Мин аның белән бик тиз үзләшеп киттем. Шунда ук аны үзебезнең өйгә алып кайтып, өебезне күрсәтергә теләсәм дә, яңа әнисе Зөһрә абыстай аны җибәрәсе килмәде: «Әле үзебездә торсын, алып барасың килсә, соңыннан алып барырсың»,— диде. Шулай да мин аны каршыдагы зиярат буена алып барып кайттым. Без бер-беребезнең исемнәребезне дә белеп алдык. Мин аңар караганда яшь ягыннан байтак кына олы һәм гәүдәгә зур булганлыктан, ул мине «Сафа абый» дип атый башлады. Без аның белән Сәгъди абзыйлар ишек алдындагы ике зур каенның берсенә мендек. Анда менгәч ул: «Тыңлап тор, Сафа абый, мин каладагыча сызгырам»,— дип, ике бармагын авызына куеп сызгырып күрсәтте. Башка балалар килә башлагач, без агач башыннан төштек. Шунда малайлар, Габдуллага төртеп күрсәтеп, «чыш-пыш» сөйли башладылар, һәм, Габдулла, алардан качып, өйгә кереп китте. Башта мин аның нәрсә өчен качканын аңламаган идем. Малайлар, аның күзенә ак төшкән булуын күреп алып, «чагыр» (кылый) дип мыскыллаганнар икән. Шулай итеп, аңа «чагыр» дигән кушамат тактылар.

Мин һәр көн Габдулла янына килеп йөрим, аны малайлардан яклый идем. Кыерсытучы малайлар булса, ул миңа килеп сыена иде. Шулай бер көнне мин аны, анасына әйтмичә генә, үзебезгә алып кайттым. Өебезне күрсәткәч, бакча артындагы әвен базына алып барып, ат кылыннан «скрипка» ясап, аңар уйнап күрсәттем. Соңыннан үзенә дә ясап бирдем. Ләкин, ачуланырлар дип, скрипканы аның ата-аналарына күрсәтмәдек. Берәр ел-

дан соң мин, зур скрипка сатып алып, бераз өйрәнә башладым. Миннән күрмәкче Габдулла да өйрәнергә тырышып карады. Ләкин аның нәни бармакларын зур скрипка кылларына куйдырып, үзеннән сыздырып, байтак маташсам да, эш чыкмады. Ахыры, булмагач, «алайса син уйна, Сафа абый, мин җырлыйм», дип, ул җырлап күрсәтте.

Кыш җиткәч без сабакка йөри башладык. Габдулла ул елны мулла абыстаена гына йөрде. Бер кыш абыстайда укыгач, икенче кышны безнең белән мәктәпкә йөри башлады. Ул, малайлар кыйнар дип, ялгызы гына мәктәпкә барырга курка иде. Мәктәпкә барышлый мин, Сәгъди абзыйларның тәрәзәсендә ут яктысы күренгәнне саклап торып, Габдулланы алып чыга идем. Ул минем керүемә бик шатлана иде.

Мәктәпкә кергәч тә, озак тормыйча, Фәтхерахман[2] мулла аны үзе укыта башлады. Безнең күбебез Хәбри[3] хәлфәдән генә укый иде. Мәктәпкә кергән елны ук Фәтхерахман мулланың Габдулланы шулай аерып укытуына без көнләшә башладык. Аның тиз арада, «Һәфтияк»[4] иҗеген укып бетереп, сүрәгә керүе һәм язга кадәр «Һәфтияк» сүрәсен бетереп «Коръән»[5] укырга башлавы безне бераз кытыкландыра иде. Чөнки башка балаларга моның өчен ике-өч ел кирәк була. Габдулланың тиз арада зур укып китүен без аның зирәклегеннән дип түгел, мулла укытканлыктан дип белә идек. Шунлыктан, Габдулланы никадәр якын күрсәм дә, мин дә аңардан көнләшә башладым. Шул елны ук ул үзеннән түбән укучыларның сабакларын өйрәтә башлады. Моңарчы бу мәктәптә андый укучы булмаганга, без аның болай укуына гаҗәпләнә идек.

Язын сабанга чыккач, Сәгъди абзый миңа Габдулланы тырмага өйрәтергә кушты. Мин аны ике көн үзем белән алып барып, тырмага өйрәттем. Кайткач, Сәгъди абзый безне бик сыйлый, «Өйрәнәме минем малай?»— дип соравына каршы: «Өйрәнә» дигәч, бик шатлана иде. Берничә көн бергәләп тырмалагач, Сәгъди абзый, туры алашасын җигеп, Габдулланың үзен генә җибәрде. Шулай да мин, аның янына барып, бераз булышкаладым. Без Иябаш[6] ягында тырмалый идек. Шул көннәрне мин малайлардан Иябашында бер кешенең эте балалаганын ишеткән идем. Шуны әйтүгә, Габдулланың колагы торды :«Әйдә барып берәр көчек алып кайтыйк, Сафа абый»,— ди башлады. Кичен, җирне тырмалап бетергәч, без Иябашына барып, икебезгә дә берәр көчек урлап

алып кайттык. Көчекләрнең берсе кара, берсе ала Габдулла үзе яратып ала көчекне алды. Көчекләрне, безнең бакча артына алып кайтып, әвенгә бәйләп куйдык. Соңыннан, атасының ачулануыннан курка-курка, ул көчеген өйләренә алып кайтты. Сәгъди абзый аны орышмады, «ташландык ипи катыларын ашатырсың шунда, барыбер күрше этләре кереп ашый. Зурайгач, йортыбызны саклар» диде. Габдулла аның бу сүзенә куанычыннан нишләргә белмәде.

Габдулла безгә бик еш килә иде. Әни, ятим дип кызганып, аңа ипи белән сөт, катык ашатып җибәрә иде. Җиләк өлгергәч, без аның белән урманга җиләк җыярга менә идек. Аңарчы шәһәрдә торганлыктан, Габдулла күп агачларның исемнәрен белми, миннән сорый иде. Аннан соң җиләкнең нинди урында күп булганлыгын да сораша иде. Үзе берәр җиләклек тапса, «Сафа абый, җиләк таптым!» дип шатланып кычкыра иде. Җиләкне ул, этисе белән әнисенә алып кайтып бирә иде. Алар: «Бик күп җыйгансың икән, улым», дип, аны мактыйлар иде. Ул моңар тагын шатлана иде.

Урак җиткәч, Сәгъди абзый Габдулланы да үзләре белән уракка алып йөри башлады. Ләкин берничә көн ургач, Габдулла бармагын кискән. Сәгъди абзыйның: «Бармагын кисмәсә, малай яхшы гына ура башлаган иде»,— дип сөйләгәне әле дә хәтеремдә.

Ничәдер ел безнең авылда торгач, Габдулла Җаек[7] каласына китте. Берничә елдан мин солдатка алындым. Шуннан соң Габдулланы күрә алмадым.

*Хәлилрахман Гобәйдуллин*

## КЫРЛАЙГА КИЛГӘНДӘ

Хәзергә кадәр чыккан китапларда язылганча, Габдулла Кырлайга 1892 елда килмәде, ә 1894 елда килде һәм аннан 1895 елда китмәде, ә 1897 елда китте[1]. Мин моны бик яхшы хәтерлим һәм, кирәк икән, документлар белән күрсәтә алам. Кырлайга килгәндә ул бик кечкенә һәм чандыр гәүдәле булса да, алты гына яшьтә түгел иде (1892 елда килсә шулай була), сигез яшьтә иде, һәм Кырлайга килгән елны ук укырга керде. Шулай ук Кырлайдан киткәндә дә тугыз яшьтә түгел, унбер яшьтә иде. Ул башта бер ел, минем әнигә йөреп, кыз балалар янында, соңыннан ике ел мәктәптә укыды. Әгәр Кырлайдан

1895 елда китсә, ул тугыз гына яшьтә киткән була. Никадәр зирәк булса да, ул яшьтә аның өч ел укуы мөмкин түгел.

Нәфисә карчык[2] белән Сафа карт[3] әйткәнчә, аны Кырлайга Сәгъди абзый хатыны Зөһрә абыстай белән Нәфисә абыстай алып кайтмадылар, Габдулла үзе язып калдырганча, аны Сәгъди абзый алып кайтты. Сәгъди абзыйның арбага кашка ат җигеп, Габдулланы янына утыртып алып кайтканын бүгенгечә хәтерлим. Нәфисә абыстайны ялганлый торган карчык дип әйтәсем килми, картлык сәбәпле аның хәтере чуалган булырга мөмкин.

Мин Габдулланың Кырлайга килүе турында шуны хәтерлим;

Без урамда балалар белән уйнап йөри идек. Җәй көне көндезге сәгать унберләр чамасы иде. Балалар: «Әнә Сәгъди абзый бер малай алып кайтып килә»,— дип кычкырып йөгерешә башладылар. Арбага кашка туры ат җиккән Сәгъди абзый, башына корама хәтфә кәләпүш кигән, чагыр күзле, маңгаенда аз гына шадралы, ябык кына бер малай утыртып, үзенең җил капкасы төбенә килеп туктады. Ат ишек алдына кергәнче үк, ул малай арбадан төшеп, безнең янга килде. Аның аягында искерәк читек белән кәвеш иде. Ул безнең белән сөйләшеп торырга өлгерә алмады, Сәгъди абзыйның хатыны чыгып, күтәреп, аны өйгә алып кереп китте. Шунда ук мин өебезгә йөгереп кайтып әткәйгә: «Сәгъди абзый Өчиледән бик шәп киенгән бер малай алып кайтты»,— дип сөйләдем. Әткәй миңа: «Ул минем белән бергә Кышкарда укыган[4] Гариф абзый улы булырга кирәк, атасы дус кеше иде, улын да күрергә кирәк»,— диде. Иртәгесен әти миңа Габдулланы өйгә алып кайтырга кушты. Мин аны барып алып кайттым. Ул бик шаян малай булып чыкты, юлда ук минем белән шаяра башлады. Бездә ул озаклап утырып, чәйләр эчеп китте. Әти белән дә яхшы гына сөйләшеп утырды. Шуннан соң ул безгә еш кына килгәләп йөри башлады. Мин дә аларга бик еш бара идем. Без аның белән бергә бик күп йөрдек. Шул елны булса кирәк, урак өстендә бик кисәк кенә авырып, вабадан аның Сабира апасы үлде[5]. Көз көне Зөһрә тәтәй аны безнең әнигә укырга китерде. Аңарчы әле мин дә укымый идем. Шул елны без аның белән, безнең аш өебездә, кыз балалар янында бергәләп әнидән сабак укый башладык. Һәр көн иртә белән аны таякка таянып йөри торган аксак Саҗидә апасы безгә укырга китерә торган иде.

Икенче кыш без Габдулла белән икебез дә мәктәпкә

йөреп укый башладык. Ул кыш Габдулла өчен бераз күңелсезрәк кыш булды. Беренчедән, ул кыш (1895 елның кышы) аны карап, тәрбияли торган Саҗидә апасы үлде[6]. Икенчедән, Сәгъди абзый хатыны үзе малай тапты. Өченчедән, шул кыш Сәгъди абзыйны паралич сугып, аның бер кулы, бер аягы зәгыйфь булып калды. Шуннан соң Сәгъди абзый семьясында Габдуллага караш үзгәреп китте. Үз улы туганлыктан, Зөһрә тәтәй аны кага башлады һәм шул кыш йортка килгән бәхетсезлекләрне (Саҗидәнең үлүен һәм Сәгъди абзыйның гарипләнүен) аннан күргән кебек итеп, «үксез бозау асрасаң, авызыңборының май булыр, үксез бала асрасаң, авызың-борының кан булыр», дип сөйләп йөри башлады. Шул елны минем әни дә бер ир малай табып, элеккечә мине иркәләми башлагач, без Габдулла белән, үзебезнең тормышыбыздан ризасызлык күрсәтеп, бер-беребезгә зарланып сөйли башладык. Зөһрә тәтәй үзенең кечкенә баласын ике тәгәрмәчле кабык арбага салып, Габдуллага карарга бирә, әни минем кечкенә энемне читәннән үргән дүрт тәгәрмәчле арбага салып, миңа бирә иде. Без җәй көне урам буенча Габдулла белән шул балаларны тартып йөри идек. Аларны ташлап китеп, иркенләп уйнап йөри алмый идек.

Мин тагын Габдулла белән икебезнең, күрше бакчасына кереп, суган урлап йөрүебезне бик яхшы хәтерлим. Берсендә безне Гаҗби исемле бер усал карчык күреп, кулына кычыткан алып куып китте. Без аннан зират киртәсенә кереп кенә котылып калдык. Шуннан соң без бик озак Гаҗби әбинең күзенә күренергә куркып йөрдек.

Габдулла безнең авылдан тик 1897 елда гына китте. Ләкин бик ашыгыч китеп барганлыктан, мин аны күрә алмадым. Тик үзе киткәч, Зөһрә тәтәйнең әнигә килеп: «Бу ни булды инде, эшкә ярамаган вакытта үз балабыз кебек тәрбияләп үстердек тә, эшкә ярый башлагач кына, килделәр дә Габдулланы алып киттеләр»,— дип сөйләгәнен хәтерлим. Киткәч, бергә уйнап йөргән балалар белән, аны сагынып сөйли идек.

1907 нче елда призывка каралырга кайтканда, Габдулла Кырлайга килгән. Ул вакытта әткәй мине призывка каралу өчен Арчага алып киткән иде. Габдулла Әтнәдә каралган булган. Ул, әни янына кереп, чәй эчеп чыккан. Өстенә яхшы пальто, башына кепка, аягына штиблет кигән булган. Үзе бик таза иде, ди. Әни аны ул кыяфәттә күреп аптырап калган. Кайткач, әнинең безгә: «Габдулла килгән иде, баштанаяк урысча киенгән, хәзер

китаплар язып торам, дип сөйләде, басылган китапларымны сезгә дә җибәрермен, диде»,— дигән сүзләре әле хәзер дә хәтеремдә.

1913 елда, авырып ятканда, әткәй Казанда Габдулланың номерына барган. Әткәй аның белән күрешү турында түбәндәгечә сөйләде:

«Мин номерына кергәндә ул, пальто ябынып, караватында ята иде... Мин кергәч, урыныннан сикереп торды да, җиткән чәчләрен төзәтеп, ике куллап минем белән килеп күреште. Звонок биреп, официантка чәй һәм пәрәмәч китерергә кушты. Үзе белән бик озаклап сөйләшеп, чәй эчтек. Минем кергәнемне бик яратты»,— диде.

Үләр елларында ул Өчилегә — анасы белән бертуган абзасы Кәбир муллага кайтып, озаклап ятса да, мин аны барып күрә алмадым. Ләкин ул вакытта Кәбир мулланың тормышы яхшы түгел иде, шунлыктан ул аны әйбәтләп тәрбияли алмаган булыр дип уйлыйм.

*Ахун Сабирҗанов*

## КҮҢЕЛДӘ ШУЛАЙ САКЛАНА

Мин Габдулланы беренче ел мәктәптә укый башлаган вакыттан беләм. Ул авыл балаларына охшамаган, бик юка гәүдәле һәм чандыр иде. Укырга искиткеч зирәк иде. Беренче кышны ук ул, «Һәфтияк» иҗеген, сүрәсен укып «Коръән»гә керде. Ул вакытта безнең мәктәптә укырга зирәклекләре белән танылган Җәббар Гарифы белән Әһлине һәм аннан берәр ел элек укый башлаган башка малайларны узып китте. Хәтта язга таба ул вакытта безнең мәктәптә балалар укытучы Хәбри хәлфә белән каты гаен[1] турында бәхәсләшә башлады. Мин мәктәптә Габдулла белән ике кыш укыдым. Һәрвакыт Габдулла, Әһли, Гариф, мин сабакны бергә укый идек, дөресен әйткәндә, Габдулла безне өйрәтә иде.

Бервакыт Габдулла белән бергәләп Сәгъди абзыйның базы тирәсендә куышып, шаярышып йөргәнлегебезне хәтерлим.

Язын алар Сәгъди абзый белән басуга чәчүгә бардылар. Без дә шуннан ерак түгел җирдә чәчү чәчә идек. Сәгъди картның арбасы янында коелып калган орлыкны чүпләргә бик күп күгәрчен җыелган. Шуны күргәч Габдулла, кул изәп, мине чакырып алды. Мин килгәч, шул

орлык коелган җиргә чәчү тубалын авызы белән каплап, кырынайтып куйдык та артына бау бәйләдек. Икебез дә бауның очын тотып арба астына кереп яттык. Тубал астына күгәрченнәр җыелгач, Габдулла миңа: «Бауны җибәр, Ахун!»— дип кычкыра. Мин бауны ычкындыргач, тубал җиргә капланып, астына күгәрченнәр кереп кала. Без аларны тотып өйгә алып кайтабыз.

Сәгъди абзый Габдуллага карата йомшак, ә хатыны Зөһрә тәтәй корырак иде. Бервакыт аларның ишек алларына кайтып, шул күгәрченнәрне очырып, шаярып йөргәнебезне күрде дә Зөһрә тәтәй, чыбык алып, безнең икебезне дә пешереп чыгарды. Шуннан соң мин Габдулладан: «Син әниеңнән ни өчен күбрәк кыен ашыйсың?»— дип сорадым. Ул: «Бервакыт әни катык биргән иде, шуны ашап утырганда бер хәерче керде дә, мин ул катыкны аңар биргән идем, шуның өчен үземне әни бик каты кыйнады»,— диде.

Габдулла Җаек каласына киткәч, берничә елдан соң мин дә Бакуга нефть промыселларына эшләргә киттем. Шунда эшләгәндә, кайдандыр минем адресны белеп, миңа хат язган иде. Мин дә аңар җавап яздым. Шуннан соң без аның белән берничә мәртәбә хат языштык. 1907 елны ул миңа: «Казанга кайттым, тиздән авылга призывка кайтам, син дә кайт, бергәләп авылга кайтырбыз»,— дип язды. Казанга кайткач, мине «Болгар»[2] номерларына, үз янына төшәргә чакырып язган иде. Шуннан соң мин дә призывка каралу өчен авылга кайтышлый Казанга тукталып, «Болгар» номерларына төштем. Ләкин мин башка номерга кергән идем. Ул, мине күргәч, аның номерына кермәвем өчен ачуланып, әйберләремне алып, мине үзенә кунарга алып чыкты, бик нык сыйлады, акчам күп булуга карамастан, бер тиен түләтмәде, бөтен ашаган-эчкәнне үзе түләде. Шуннан соң төне буе сөйләшеп яттык. Ул Уральск хәлләрен сөйләде, мин Баку хәлләрен сөйләдем. Икенче көнне, үз кесәсеннән извозчик яллап, мине музейга, киного алып барды, кичен циркка бардык. Аннан кайткач, тагы бик нык сыйлады.

«Без никрутлар бит, малай, эч!» — дип аркамнан кагып, мине сыйлауларын әле дә онытмыйм. «Өч көнсез җибәрмим», дисә дә, икенче көнне мин ашыгып Кырлайга кайтып киттем, ул Кушлавычка кайтырга калды. Үзен көтми кайтып киткән өчен миңа үпкәләп калды.

Әһли белән мине солдатка алдылар, Габдулла котылып калды. Солдатка алынгач ай ярымнан соң без Әһли

белән, китү өчен, Казанга военный начальникка килдек. Безнең Казанга килгәнне белеп, Габдулла яңадан үз номерына чакырды. Озаклап сөйләшеп утырдык. Безне бик сыйлап җибәрде. Казаннан бик тиз китмәгәнгә, тагын берничә тапкыр аның номерына барып сөйләшеп утырдык. Шул утырышулар Габдулла белән актык утырышу булды. Шуннан соң без аны күрә алмадык.

*Хәбибрахман Гатауллин*

## ЗИРӘК ШӘКЕРТ

Мин Габдулланы мәктәпкә укырга кергән көннән башлап беләм. Мәктәпкә йөри башлаганда ул бик кечкенә иде. Укырга кергәч башта аны мин укыттым. Соңыннан гына ул муллага күчте. Укуга һәм язуга бик зирәк, ятлау куәсе көчле иде. Табигате басынкы, дәртле иде. Башка балалар белән тәрбиясезләнеп, шаярып йөргәнен хәтерләмим. Шаярган яки сабак белмәгәне өчен минем тарафтан башка балаларга кыен эләккәләсә дә, аңар тырнак белән дә чиртмәдем. Башта ул мәктәпкә йөреп кенә укыды, соңыннан кунып укый башлады. Сабагын белмәсә, хурланып елый иде. Бервакыт кара савытын ваткан өчен елады. Мин аны юатып, башка кара савыты бирдем. Габдулла аңа бик куанды. Бераз укыгач, ул мәктәптәге башка балаларның сабакларын өйрәтә башлады.

Безнең өйгә һәрвакыт кереп-чыгып йөри иде. Бигрәк тә минем туган абзам Фәтхерахман муллага еш кереп йөри иде. Габдулла Казанда торганда минем абый (Фәтхерахман мулла) аның янына барып йөри иде. «Болгар» номерларында авырып ятканда да, ул аның янына барган. Габдулла аңа чәй белән пәрәмәч китерткән. Ләкин үзе ашый алмаган. Шуннан соң ул озак тормый үлде.

Призывка каралырга кайткач, бер иптәше белән Кушлавычтан ашыгыч кына Кырлайга килгән иде. Фәтхерахман абзый өйдә булмагач, үзе генә кереп, әзер самовардан минем өйдә бер-ике чынаяк чәй эчеп чыгып китте. Кунарга кыстасам да: «Атыбызны да туармадык, иптәшем көтә, ашыгыч»,— дип, китте. Үзе бик тазарган, бик матурланган иде. Өс-башы да бик чиста иде.